КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1283

2024 елда Яр Чаллы шәһәренең «Гали Акыш исемендәге 84 нче интернат лицей» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең матди-техник базасын ныгыту өлешендә муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Яр Чаллы шәһәр округы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы булган субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елда Яр Чаллы шәһәренең «Гали Акыш исемендәге 84 нче интернат лицей» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең матди-техник базасын ныгыту өлешендә муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә,

башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Яр Чаллы шәһәр округы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы булган субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 декабрь, 1283 нче
карары белән расланды

2024 елда Яр Чаллы шәһәренең «Гали Акыш исемендәге 84 нче интернат лицей» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең матди-техник базасын ныгыту өлешендә муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Яр Чаллы шәһәр округы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы булган субсидия бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2024 елда Яр Чаллы шәһәренең «Гали Акыш исемендәге 84 нче интернат лицей» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең матди-техник базасын ныгыту өлешендә муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Яр Чаллы шәһәр округы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы булган субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – муниципаль берәмлек, субсидия) бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Субсидия җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру буенча барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Яр Чаллы шәһәренең «Гали Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернат» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең матди-техник базасын ныгыту өлешендә бирелә.

3. Финанслашу максаты белән субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше – муниципаль белем бирү оешмасы өчен җиһаз, инвентарь һәм җайланма сатып алу.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

5. Субсидия муниципаль берәмлек бюджетына бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

6. Субсидия бирү түбәндәге шартлар үтәлгәндә гамәлгә ашырыла:

финанслашу максаты белән субсидия бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый акты булу;

муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча йөкләмәсе карала торган Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү һәм әлеге килешү белән каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

7. Муниципаль берәмлек бюджетына 2024 елда бирелә торган субсидия күләме 20 295,0 мең сум күләмендә билгеләнә.

8. Бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгәннән соң, Министрлык муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органына субсидия бирүгә заявкалар (алга таба – заявка) бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша электрон документлар рәвешендә кабул итү турында хәбәрнамә җибәрә.

9. Субсидия алу өчен муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы, заявкалар кабул итү турында хәбәрнамә алынган көннән алып бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша электрон документлар рәвешендә түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле формада заявка;

финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган муниципаль берәмлекнең хокукый актыннан өземтә;

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турындагы законнар нигезендә кыйммәте нигезләнгән җиһаз, инвентарь һәм җайланма сатып алу чыгымнары сметасы.

Заявка муниципаль берәмлек башлыгы яисә аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән башка вазыйфаи зат тарафыннан имзалана.

10. Әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлык тарафыннан кергән көнне аларның керү вакытын һәм датасын күрсәтеп теркәүгә алына.

11. Әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән документларны аларның комплектлылыгы предметына, аларда булган мәгълүматның тулылыгына, шулай ук муниципаль берәмлекнең әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган шартларга туры килүенә карау һәм субсидия бирү турында йә субсидия бирүдән баш тарту турында карарлар кабул итү шушы документлар теркәлгән көннән алып ике эш көне эчендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Карар Министрлык тарафыннан боерык формасында кабул ителә.

12. Кабул ителгән карар турындагы мәгълүмат Министрлык тарафыннан

боерык раслаган көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына хәбәрнамә җибәрү юлы белән җиткерелә.

13. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

муниципаль берәмлекнең әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган шартларга туры килмәве;

муниципаль берәмлек тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 9 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

14. Субсидияләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып әзерләнә (формалаштырыла) һәм төзелә торган субсидияләр бирү турындагы килешү нигезендә бирелә.

Муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәсен субсидия акчасы исәбеннән финанслашу дәрәҗәсе 99 процент тәшкил итә.

15. Субсидия күчерү Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына килешү төзегән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

16. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы Министрлыкка килешүләрдә билгеләнгән формалар буенча һәм сроклар эчендә финанслашу максатларында субсидия бирелә торган җирле бюджет чыгымнарын гамәлгә ашыру турында, шулай ук субсидиядән файдалану нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисапларны тапшыра.

17. Хисап финанс елында субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан хисап чорында муниципаль берәмлек тарафынна әлеге Тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән килешүдә билгеләнгән субсидиядән файдалану нәтиҗәсенең план буенча һәм фактта ирешелгән күрсәткече нигезендә гамәлгә ашырыла.

18. Субсидиядән файдалану нәтиҗәсе – муниципаль берәмлек тарафыннан Яр Чаллы шәһәренең «Гали Акыш исемендәге 84 нче интернат лицей» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесен җиһазлау өчен җиһаз, инвентарь һәм җайланма сатып алуның әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән, бирелгән субсидия күләменә һәм спецификациясенең микъдар һәм сыйфат тасвирнамәләре буенча тиешле җиһаз, инвентарь һәм җайламан исемлеге бирелгән килешүгә туры килүе.

Субсидиядән файдалану нәтиҗәсенә 2024 елның 31 декабренә кадәр ирешелергә тиеш.

19. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидиянең максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

20. 2025 елның 1 гыйнварына карата файдаланылмаган субсидия 2025 елның 15 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

21. Субсидиянең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә түләтелергә тиеш.

22. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидия бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан әлеге Тәртипнең 20 пунктында күрсәтелгән субсидия акчасы Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган бюджетка мәҗбүри түләтү чаралары кулланыла.

23. Субсидиядән максатчан файдалануны, субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүдә тоту Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.